«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ

2022 елның 25 октябрендәге №68

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында нигезләмәне раслау хакында" 2018 елның 19 апрелендәге 73 номерлы (2018 елның 07 июнендәге 79 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 97 номерлы, 2019 елның 07 июнендәге 118 номерлы, 2020 елның 30 сентябрендәге 7 номерлы карарлар редакциясендә)карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль берәмлекләрнең рәисләре, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгының урынбасарының айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 декабрендәге 182 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфаларына туры китереп, 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләү һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләү.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районының Сөкәй авыл җирлеге башлыгы, Кама Тамагы районының Сөкәй авыл җирлеге Советы рәисе
П.В. Сорокин